ГЛАВА ДЫМ-ТАМАКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
с.Дым-Тамак, ул.Новая, д.4в, 423955

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ДИМТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Димтамак авылы, Яна урам, 4 в йорт, 423955

Тел.:(85593) 4-52-37, факс:4-52-37, e-mail: Dtam.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«24» октябрь 2025 ел № 6

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Димтамак авыл җирлеге составына керүче Димтамак торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Димтамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 26, 92 маддәләре нигезендә, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Димтамак авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында»гы нигезләмәгщ таянып, КАРАР БИРӘМ:

1. 2025 елның 10 ноябрендә 14.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы, Ютазы муниципаль районы, Димтамак авылы, Яңа урам, 4в санлы йорт адресы буенча урнашкан күпфункцияле үзәк бинасында Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлегенең Димтамак торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«2026 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Димтамак авыл җирлеге Димтамак торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 һәм 2 төркем инвалидлардан, сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан, сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарыннан, Россия армиясе сафларында хезмәт итүче хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә сез ризамы:

- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү, электр энергиясен тапшыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (Димтамак торак пунктында урамнарны яктырту фонарьлары сатып алу һәм урнаштыру);

- Димтамак торак пунктында торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (грейдерлау, юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен

запас частьләр сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен шартнамә буенча түләү));

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Димтамак торак пунктының юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү (реконструкция, асфальт салу, ремонтлау, вак таш салу, ташу, төзелеш материалларын сатып алу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү).

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Димтамак авыл җирлеге башкарма комитетына Димтамак торак пунктында гражданнар җыенын оештыруны һәм үткәрүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә (http://jutaza.tatarstan.ru.), Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru / электрон адресы буенча кабул ителгән көннән алып 5 көн эчендә урнаштырырга.

5. Әлеге карар рәсми игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Димтамак авыл җирлеге башлыгы Җ.Ә.Хөснетдинов